| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>Село Янурусово, улица Ленина, дом 43а,<br>423370 Телефон 4-10-19 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>Ленин урамы,43а йорт, Янурыс авылы,<br>423370 Телефон: 4-10-19 |
|---|---|

ОГРН 1031604000757 ИНН/КПП 1636001403/163601001 ОКАТО 92253884000


РЕШЕНИЕ КАРАР
24.09.2018 № 19

**Янурыс авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында.**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п. 1 пункты, Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге советы карары нигезендә «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» Сарман муниципаль районының 2016 елның 28 сентябрендәге 15 номерлы карары нигезендә Янурыс авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 18 ноябренә Янурыс авыл хуҗалыгы территориясендә гражданнарның үзара салымын алып бару мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:
«1 төркем инвалидлардан тыш, Янурыс авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез ризамы:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп тору, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

-Янурыс авылында, Каташ-Каран авылында урамнарны яктырту өчен диодлы лампочкалар сатып алу һәм урнаштыру;

-МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, частьләр запасы сатып алу, машина йөртүченең хезмәте өчен түләү);

- Янурыс авылы мәдәният йорты территориясендә брусчатка ясау.

2) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

- Янурус авылы зиратында зур агачларны кисү

3) Ял итү оешмалары һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

- чаралар уздыру өчен бүләкләр сатып алу (Янурыс авылында Каташ-Каран авылында «Сабантуй», Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Җиңү көне, );
4) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Янурыс, Каташ-Каран авылларында юл билгеләре, ясалма тигезсезлек сатып алу һәм урнаштыру.

5) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

-Каташ-Каран авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

"ӘЙЕ" "ЮК" ?.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Янурыс авыл җирлеге
Советы рәисе А.А.Мөхәмәдиева